ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

3 декабрь, 2025 ел № 3/11

2026 елга Яр Чаллы шәһәре муниципаль
милкен хосусыйлаштыру Фараз планын
(программасын) раслау турында

«Дәүләт һәм муниципаль милекне хосусыйлаштыру турында» 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль закон, «Дәүләт һәм муниципаль унитар предприятиеләр турында» 2002 елның 14 ноябрендәге 161-ФЗ номерлы Федераль закон, Шәһәр Советының 2011 елның 25 августындагы 13/11 номерлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль милкен хосусыйлаштыру тәртибе турында Нигезләмә нигезендә

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. 2026 елга Яр Чаллы шәһәре муниципаль милкен хосусыйлаштыру Фараз планын (программасын) кушымтага нигезләнеп расларга.
2. Әлеге Карарның үтәлешен контрольдә тотуны Шәһәр Советының социаль-икътисадый үсеш мәсьәләләре һәм бюджет буенча даими комиссиясенә, Башкарма комитет Җитәкчесе Ф.Ш. Салаховка йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев

Шәһәр Советының
3/11 Карарына
кушымта
3 декабрь, 2025 ел

# 2026ЕЛГА ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ МУНИЦИПАЛЬ МИЛКЕН ХОСУСЫЙЛАШТЫРУ ФАРАЗ ПЛАНЫ (ПРОГРАММАСЫ)

## 1 бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1. 2026 елга Яр Чаллы шәһәре муниципаль милкен хосусыйлаштыру фараз планы (программасы, алга таба – Фараз планы) «Дәүләт һәм муниципаль милекне хосусыйлаштыру турында» 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль законга, Шәһәр Советының 2011 елның 25 августындагы 13/11 номерлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль милкен хосусыйлаштыру тәртибе турында Нигезләмәгә (алга таба - Нигезләмә) туры китереп эшләнгән.

2. 2026 елда Яр Чаллы шәһәре муниципаль милкен хосусыйлаштыру Яр Чаллы шәһәренең муниципаль милек структурасын оптимальләштерүгә, хосусыйлаштыру объектларына инвестицияләр җәлеп итүгә, шәһәр бюджеты керемнәрен арттыруга юнәлтелгән.

3. Нигезләмәгә туры китереп, муниципаль милекне хосусыйлаштыруны законда каралган ысуллар белән башкару күздә тотыла.

## 2 бүлек. Хосусыйлаштырылырга тиешле муниципаль милек

4. 2026 елда муниципаль казнада булган, муниципаль предприятиеләр һәм учреждениеләр тарафыннан максатчан кулланылмаган күчемсез милек хосусыйлаштырылырга тиеш.

5. 2026 елда Шәһәр Советының 2024 елның 6 декабрендәге 28/11 номерлы Карары белән расланган 2025 елга Яр Чаллы шәһәре муниципаль милкен хосусыйлаштыруның Фараз планына (программасына) кертелгән һәм агымдагы елда хосусыйлаштырылмаган объектлар хосусыйлаштырылырга тиеш.

6. Күчемсез милекне хосусыйлаштыру һәм хосусыйлаштыру шартлары турында, шул исәптән милекне тартып алу белән бер үк вакытта мондый милекне сатып алучы затка сату башкарылганда, әлеге милек биләгән һәм аннан файдалану өчен зарур булган җир участогын хосусыйлаштыру шартлары турында карар Шәһәр Советы карарлары нигезендә Башкарма комитет Җитәкчесе тарафыннан кабул ителә.

7. Фараз планының гамәлдәге вакытында 2026 елда хосусыйлаштыру планлаштырылган муниципаль күчемсез милек исемлегенә Шәһәр Советы Карарлары нигезендә үзгәрешләр кертелергә мөмкин.